**Пилотсыз очучы аппаратлар һөҗүм итү вакытында халыкның гамәлләре турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Күрсәтмә**

**Урамда булганда:**

характерлы тавыш ишетеп, очып баручы пилотсыз очучы аппарат силуэтын күргәч, түбәндәге гамәлләр тәкъдим ителә:

үз куркынычсызлыгыңны тәэмин итәргә, күз күреме зонасын (куркыныч зонаны) ташлап китәргә, мөмкин булганча зигзаглап йөгерергә;

кичекмәстән якындагы корылмага (бина, яшеренү урыны, подвал, җир асты кичүе яки паркинг бинасы), агачлар артына, стена артына һ. б. җирләргә качырга;

шартлаткыч матдәләрен ташлаганда читкә йөгерергә, якындагы корылмада, бетон стена, койма нигезе, бордюр артына качарга, алар булмаганда - җиргә, канауга яки чокырга ятарга һәм куллар белән башны капларга;

беренче шартлаудан соң күтәрелмәскә, читкә тәгәрәргә яки шуышырга;

пилотсыз очучы аппарат төшкәндә аңа яки аның калдыкларына кагылмаска: алар шартларга яки агулы булырга мөмкин.

**Өйдә (бинада) булганда:**

пилотсыз очучы аппарат һөҗүме вакытында өйдә (бинада) булганда, мөмкин булганча иң аскы катларга, подвалга яки җир асты паркингына төшәргә кирәк;

пыяладан торган элементлары булган заманча биналар бик куркыныч, - шартлау очрагында мондый корылма ишеләчәк, ә пыяла бик күп вак очлы кыйпылчыкларга ватылачак;

фатирда булганда тәрәзә ерак булган урын табарга кирәк, стеналар арасында, кагыйдә буларак, бу ванна бүлмәсе, чулан, аннары идәнгә утырырга кирәк;

**Тәрәзә янына килү катгый тыела!**

**Лифтка керергә ярамый!**

торак-коммуналь хуҗалык органнары (идарәче компания) тарафыннан әзерләнгән һәм шул максатлар өчен каралган саклау корылмасына (качу урынына) тиз арада качырга;

**Саклау корылмасы алдан җайлаштырылган, җиһазландырылган һәм качучы кешеләрне кабул итүгә әзерләнгән булырга тиеш!!!**

саклау корылмасы булмаганда подвалга төшәргә;

**Подвалның ике чыгу юлы булырга һәм вентиляциясе эшләргә тиеш!**

әгәр ышык урын (подвал) юк икән - бинаның аскы (цоколь) катына төшәргә, тәрәзәсез бүлмә, терәк диварлар арасындагы урын табарга, идәнгә утырырга һәм иелергә.

**Транспортта:**

транспортта баручыларга, аны ташлап, якындагы ышык урынга качарга кирәк; автомобильне (транспорт чарасын) туктатырга, якындагы ышык урынга качырга; ышык урын булмаганда җиргә, канауга яки чокырга ятарга һәм куллар белән башны капларга.

**«Внимание! Республика Татарстан! Опасность атаки БПЛА» сигналын алгач:**

**Социаль әһәмиятле объектларда һәм кеше җыелу урыннарда:**

социаль әһәмиятле объектларда һәм кеше җыела торган урыннарда барлык чараларны туктатырга;

Пилотсыз очучы аппарат һөҗүме һәм эш итү тәртибе турында хәбәр итүне объектлы сөйләм системасы (хәбәр бирү җайланмасы) буенча тавыш хәбәрен тапшыру юлы белән оештырырга;

Пилотсыз очучы аппарат һөҗүме очрагында гамәлләр тәртибе турында объект инструкциясендә каралган чараларны башкаруга керешергә (алда — инструкция);

бүлмәләрне электрсыз калдырырга (электр приборларын сүндерергә, утны сүндерергә);

тәрәзәләрне һәм ишекләрне ныклап ябарга;

икенчел зарарлаучы элементлардан (пыяла кыйпылчыклары һәм бина конструкциясе ватыкларыннан) җәрәхәт алмас өчен тәрәзәләрдән һәм тышкы диварлардан мөмкин булган максималь ераклыкта торырга;

инструкциядә каралган икенчел зарарлаучы элементлардан саклану чараларын кулланырга;

алдан җайлаштырылган һәм җиһазландырылган ышык урыннарны кешеләрне кабул итүгә әзерләргә;

пилотсыз очучы аппарат очып килү очрагына һаваны күзәтү өчен объектлар (учреждениеләр, оешмалар) периметры буенча тотрыклы элемтә белән күзәтү постлары куярга;

үзең белән яшеренергә шәхси документларны, булган индивидуаль саклану чараларын, дару тартмасын, элемтә чараларын, кирәкле су һәм азык-төлек запасын (булган очракта) алырга;

булган индивидуаль саклану чараларын әзер тотарга;

кешеләрне гамәлләр белән идарә итү өчен тотрыклы элемтәле һәр төркемдә 15 кешедән артмаган яшеренү төркемнәренә таратырга;

тиз арада, паникага бирелмичә, уяулыкны һәм тынычлыкны саклап, яшеренүчеләр төркемнәрен биналардан чыгарырга;

эвакуация урыннарында яшеренүчеләр төркемнәрен тупларга, билгеләнгән сигнал буенча яшеренү урыннарына качарга әзер булырга;

эвакуация урыннары буларак биналарның аскы катларындагы коридорларда тәрәзәсез бүлмәләрне, терәк диварлар белән сакланган урыннардан мәҗбүри тәртиптә файдаланырга;

куркынычсызлык чаралары турында һәм алдагы гамәлләр тәртибе буенча яшеренүчеләр төркемнәре белән инструктажлар үткәрергә;

медицина персоналын әзерлеккә китерергә һәм медицина ярдәме күрсәтү чаралары белән эвакуацияләү урыннарына җибәрергә;

**«Отбой атаки БПЛА»** сигналын алганчы яшеренү урыннарыннан чыкмаска һәм аларны ташлап китмәскә.

**Яшеренү урыннарына качу хәбәрен (сигналын) алгач:**

җитәкче состав яшеренү урыннарына качуга билгеләнгән сигнал бирә; яшеренүчеләр, җаваплы хезмәткәр күрсәтмәләре нигезендә, алдан әзерләнгән, шул максатлар өчен җайлаштырылган һәм җиһазландырылган яшеренү урыннарында урын алалар;

**«Отбой атаки БПЛА»** сигнал алганчы яшеренү урыныннан чыкмаска һәм аны ташлап китмәскә.

**Объект (учреждение, оешма) территориясенә пилотсыз очучы аппарат төшкәндә:**

шунда ук ашыгыч оператив хезмәтләренең «112» бердәм чакыру номеры буенча шалтыратырга. Хәбәр итүченең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аппаратның табылган вакытын, урынын (адресын) һәм оператор сораган башка мәгълүматларны хәбәр итәргә, шулай ук вакыйга турында җитәкчелеккә (персоналга) җиткерергә;

пилотсыз очучы аппарат төшкән урыннан куркынычсыз ераклыкта торырга һәм ашыгыч оператив хезмәтләр килгәнче аңа беркемне дә китермәскә;

ашыгыч оператив хезмәтләрнең вакыйга булган урынга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

ашыгыч оператив хезмәтләр килгәч, аларның күрсәтмәләре буенча эш итәргә;

төшкән пилотсыз очучы аппарат янында булганда радиоаппаратура, мобиль телефоннар, GPS/ГЛОНАСС җайланмаларыннан файдаланырга, шулай ук фотога төшерү һәм пилотсыз очучы аппарат төшкән урынның сурәтләрен челтәргә салу **катгый тыела**;

җитәкче состав командасы буенча **«Внимание! Республика Татарстан! Отбой атаки БПЛА» сигналын алынгач**, яшеренү урыныннан китәргә һәм аның күрсәтмәләре нигезендә эш итәргә.

Пилотсыз очучы аппарат һөҗүмнәре турында ашыгыч мәгълүматны (push-хәбәрләр рәвешендә) Android һәм IOS операцион системалары базасындагы мобиль җайланмаларны кулланучылар «МЧС России» мобиль кушымтасыннан алырга мөмкин. Ул RuStore, Google Play, AppGallery һәм App Store кушымталары кибетләрендә бушлай кую өчен мөмкин. Мобиль кушымтаны табу, кую һәм аның белән эшләү өчен, кулланучының җентекле кулланмасы Россия ГТХМ сайтында урнаштырылган.